АЛЕКСЕЕВСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07.10.2024 № 268

п.г.т. Алексеевское

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирлекләренең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Уставы нигезендә

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар итте:**

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирлекләрнең түбәндәге вәкаләтләренең бер өлешен Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары тәкъдимен кабул итәргә (1 нче кушымта):

-җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен раслау;

- җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү.

2. Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетына:

- әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне типовой форма нигезендә тапшыру турында Алексеевск муниципаль районы җирлекләренең башкарма комитетлары белән килешү төзергә (2 нче кушымта);

- әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Алексеевск муниципаль районы бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турында Алексеевск муниципаль районы Советы карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тапшырырга.

3. Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнары әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән Килешүне гамәлгә ашыру өчен үз компетенцияләре чикләрендә норматив һәм норматив булмаган хокукый актлар чыгарырга хокуклы дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында хокукый акт текстын урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә .

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Муниципаль район башлыгы,**
**Совет Рәисе** **С. А. Демидов**